**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЮТАЗИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АБСАЛЯМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423957, Республика Татарстан,
Ютазинский район, с.Абсалямово,
ул. Молодежная д.2
тел./факс: 4-26-79

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
423957,Татарстан Республикасы,
Ютазы районы, Әбсәләм авылы,
Яшьләр урамы, 2
тел./факс: 4-26-79

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
№ 2 31 январь 2023 ел

2023 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм күмү эше турында» 8-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 57 санлы карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы 196 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Әбсәләм авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авылы Башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. 2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен әлеге карарның 1 нче кушымтасы һәм 7 нче кушымтасы нигезендә, 7793,48 (җиде мең җиде йөз туксан өч сум 48 тиен) суммасында билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы «2022 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»гы 2 санлы карарын үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Әбсәләм авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы сайтында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының “Татарстан Республикасы рәсми порталы” Бердәм порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru/

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның “31” январе
2 санлы карарына

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Әбсәләм авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәтләр исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3115,52 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 952,3 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3725,66 |
| Барлыгы | 7793,48 |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның “31” январе
2 санлы карарына

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәт исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда ) |
|---|---|
| 1. Мәетне күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җәсәдне кәфенгә төрү | 723,02 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2392,5 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 952,3 |
| 5. Кабер казу һәм күмү) | 3725,66 |
| Барлыгы | 7793,48 |